

*Ягъфәр Хисмәтуллин (сулда) һәм Хисаметдин Исмәгыйлев һәйкәлгә чәчәк сала.*

– Шушы мәдрәсәләрне үз акчасына тоткан Мөхәммәтшакир Тукаев үзе генә дә әллә ничә шәхескә торырлык. Патша хөкүмәтенең ике чакырылыш Думасында депутат та булган.

Ягъфәр абый, тагы да сүзгә кушылып:

– Менә бу шәп идея! Чынлап та, Тукаев истәлегенә берәр нәрсә эшләп куя алсак, Стәрлебаш мәдрәсәләрендә укыган барча атаклы шәхесләргә дә һәйкәл булыр иде бу, – ди.

Мин дә абзыйларны куәтлим:

– Әйе, абзыйлар, бу бик шәп фикер! Моны башкарып чыгарга кирәк. Ичмаса, шушы Стәрлебаш мәдрәсәләрен искә төшереп, аларның данын саклап торучы һәйкәл булыр иде.

Зәки абый инде, безне дәртләндереп:

*Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ*

# *Һәйкәлләр – тереләр өчен...*

*Стәрлебаш авылында тел хезмәтчәннәренә багышланган скульптур ансамбль һәм Мөхәммәтшакир Тукаев һәйкәле көндәлегеннән*

...Беркөн шулай Ягъфәр абый белән икәүләп Зәки абыйның хәлен белергә бардык. Тегесен-монысын сөйләшеп, озак кына чәйләп утырганнан соң Зәки абзый:

– Әй, егетләр, онытып торам бит. Сезгә бер нәрсә күрсәтим әле, – дип, урыныннан торып, икенче бүлмәсеннән, бик матур итеп агачтан эшләнгән хатын-кызлар сыны композициясен алдыбызга китереп куйды. Без Зәки аганың агачтан төрле-төрле сыннар эшләгәнен белә идек. Әмма бу эше бигрәк тә шәп килеп чыккан. Һәм ул аңлатырга да тотынды.

– Менә, – ди, – бусы Гайшә, ә менә бусы Кара Гобәй хатыны – дип, барча сыннарның исемнәрен атап чыкты. – Минем "41нең арбалы хатыннары" дигән пьесаның төп геройлары менә шушылар инде, – ди.

Шулай матур гына сөйләшеп утырганда, Ягъфәр абый белән икебез дә, сүз куешкан кебек, берьюлы сөйли башлыйбыз.

– Ә бит, Зәки абзый.... – Мин, Ягъфәр абзыйга хөрмәт йөзеннән, туктап калдым.

Ягъфәр абый, Зәки Зәйнуллинга карап:

– Безнең Стәрлебашта районның данын ерак-еракларга тараткан атаклы шәхесләребезне халыкка күрсәтерлек бер истәлекле тактаташыбыз да, берәр тарихи бинабыз да юк икән! – ди.

Шунда Зәки ага, гадәтенчә, бераз кыза биреп:

– Ә бит Стәрлебаш мәдрәсәсен бетергән әллә ничә күренекле шәхес бар. Алар шушы мәдрәсәләрне бетермәсә, кем булыр иде икән? Мөселман дөньясы нинди атаклы шәхесләрдән мәхрүм калган булыр иде. Санап китәм, менә алар: Пугач патшаның баш полковнигы Кинҗә Арсланов; Юлай Казналы (Азналин), полковник; Салават Юлай улы, полковник; Канзафар Усаев, полковник; Бөрҗән ыруы башкорты Каранай Морат. Стәрлебаш мәдрәсәсендә Мифтахетдин Акмулла да укыган. Суфи шагыйрь Шәмсетдин Зәки, Мөхәммәтгали Чокрый һәм Габдрәхим Утыз-Имәни дә монда белем алган. Шәмсетдин Зәки белән Гали Чокрый шәкертләргә белем биргәннәр. Һәм башка, һәм башка бик күп шәхесләр укыган безнең мәдрәсәләрдә, – дип, Зәки ага сөйләвен дәвам итә.

– Бу эшкә сез икегез тотынсагыз, булдыра алырсыз, егетләр, дип уйлыйм, – дип, безнең күңелләрдә кабына башлаган утка кәрәчин сибеп җибәрде.

Һәм без шушы идеяне, ягъни Мөхәммәтшакир Тукаевка һәйкәл кую нияте белән яна башлап, төрле планнар корабыз. Безнең халыкта "Ният – эшнең яртысы" дигән әйтем бар. Җиң сызганып эшкә керешәбез.

Иң тәүдә бу турыда гариза һәм тәкъдим белән район башлыгына керәбез. Ул безгә аптырабрак карап тора. Шулай да безнең белән җылы гына сөйләшә. Мөхәммәтшакир Тукаев турындагы кыскача белешмәне һәм гариза-үтенечне алдына салабыз.

Һәйкәл мәшәкатьләре белән йөргән арада безнең башка тагы бер уй килде. Монысы инде Казан шәһәрендә булды. Бөтендөнья татар конгрессына кереп, Мөхәммәтшакир Тукаевның бюстын нинди скульптор эшли алыр икән, дип сөйләшергә барган идек. Шунда Казан Кремле диварыннан аста, ат арбасына балалар утыртып китеп барган абзый кеше скульпту-

расына тап булдык. Бу һәйкәлдә Әсгать Галимҗанов дигән кеше сурәтләнгән. Һуш китмәле хәл! Ул үз акчасына алган автобусларны балалар йортларына бүләк итә торган булган. Шулай итеп, барлыгы сиксән автобус бүләк иткән. Ятимнәрне атына утыртып йөртеп, аларның күңелләрен күтәрә торган булган. Башка ярдәмяхшылыкларын санап та бетерерлек түгел. Шунда безнең башта яңа идея туды. Нигә әле үзебезнең әби-апаларга да шундый һәйкәл куймаска? Безнең болай канатланып йөрүгә Уфа комиссиясенең Мөхәммәтшакиргә һәйкәл куярга дигән тәкъдимгә уңай җавап биреп, скульпторларның да ярдәм вәгъдә итүләре сәбәпче булды.



*Һәйкәл күренеше.*

Казан каласыннан кайткач, шушы идея белән канатланып, яңадан район башлыгына кердек. Илдар Миңнеәхмәт улы безнең бу тәкъдимгә тиз ризалашты. Кәефе дә әйбәт күренә. Һәм безгә сорау бирә:

– Ә Тукаев бюстын кайчан куясыз?

Бу сорауга биреләчәгенә әзер идек.

– Без бу эшләрне параллель эшләргә булдык. Казан ерак. Һавадагы торнага ышануга караганда, кулдагы чыпчык яхшырак. Үзебезнең Уфада яхшы скульпторлар таптык. Җитәкчесе Г. В. Лобанов дигән кеше. Безгә бу скульпторны Төзелеш һәм архитектура министрлыгыннан тәкъдим иттеләр, – дибез.

– Ярар, алай булгач, сез шушы үз эшләрегез белән шөгыльләнә торыгыз. Ә без бу яңа тәкъдимегез буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрербез. Шунсыз булмый, – ди.

Бераз артка чигенебрәк язам. Сугыш башлангач, Стәрлебаштан сугышка алынган ирләр хәрби әзерлек лагеренда ачтан интегә, дигән хәбәр хатыннарны зур кайгыга сала. Ирләрен ашатырга була, хатыннар ат арбасын үзләре тартып, Раевкага азык-төлек алып бара. Һәм андый хатыннар Стәрлебаш районында гына да әллә ничә. Яңгырчы авылыннан Кәримова Рабига апа, ике бала утыртып бәләкәй арбага азык-төлек төяп, Алкиндагы лагерьга бара. Айдарәле, Тәтер-Арслан һәм Куганакбаш авылыннан Ишмиярова Саҗидә апа, Ишмиярова Нәкыя, Усманова апалар. Түбәнге Аллагуват авылыннан, башка авыллардан баручылар да булган.



*Сулдан уңга: **иганәчеләр Рамил Тукаев, Наил Мәхмүдов, Стәрлебаш районы хакимиятенең элекке башлыгы Илдар Локманов, Стәрлебаш районы хакимияте башлыгы Рөстәм Рахмангулов, Ягъфәр Хисмәтуллин, Хисаметдин Исмәгыйлев.***

Уфадагы скульпторлар белән тагы очрашып сөйләштек. Алар Стәрлебашка килеп бу һәйкәл куелачак урынны да карап билгеләде. Район башлыгы һәм Мәдәният сарае директоры белән килешеп, һәйкәлне район Мәдәният сарае алдына куярга сүз куештык. Скульпторлар бу җәһәттән – тәҗрибәле кешеләр. Алар һөнәри күзлектән карап хәл итте. Югыйсә, башка урынга куярга дигән тәкъдимнәр дә бар иде. Боз кузгалды. Красноуфимск каласына барып, бронзадан сын коючы осталар белән дә очрашып, бәйләнешкә кереп, сөйләшүләр алып бардык. Тиз арада композициянең кече макетын эшләделәр. Эш башлау өчен бер миллион акча кучердек. Тәүге акчаны, башлап, Зәки абзый үзе бирде.

Җәмәгать тыңлауларын кәтәкәтә көз дә җитте. Кәтмәгәндә, районга яңа башлык килде. Яшь, эшлекле кеше. Беренче кереп сөйләшкәндә, Рөстәм Камил улы безнең ниятләрне хуплап, дәртләндереп чыгарды.

– Бик шәп идея! Мин бу ниятегезне хуплыйм, – диде.

Икенче җәмәгать тыңлауларында 27 кеше катнашты. Шулардан 24 кеше безнең өчен, ягъни риза дип кул күтәрде.

Шушы елның, ягъни 2019 елның сентябрь аенда Турмай авылында районның татар мәдәнияте көннәре үтте. Мин, районның татар җәмәгатьчелеген җитәкләүче бу-

ларак, һәйкәл урнаштыру буенча булган мәсьәләне дә көн тәртибенә керттердем. 120 кеше катнашлыгында үткән бу җыелыш, бертавыштан, һәйкәлне куярга кирәк, дигән карар чыгарды.

Ниһаять, мәсьәләне район Советы президиумына куярга булдылар. 2019 елның 24 октябрендә президиум утырышы булды. Тавышка куйдылар. Әмма безнең мәсьәләне бертавыштан "билгесез вакытка кичектереп торырга" дигән карар кабул ителде. Сәбәбе Мөхәммәтшакир Тукаевка һәйкәл куелмауда иде, тәүдә аны урнаштырыгыз, аннан карарбыз, диләр. Ул да булса, районда һәйкәлне куюга каршы кешеләр бар булып чыкты.

Ягъфәр абый:

– Соң, бит бу ике эшне дә скульпторлар параллель алып бара. Киләсе елга – Бөек Җиңүнең 75 еллыгы. Менә шул датага "Арбалы хатыннар"ның һәйкәлен эшләп бетерергә иде исәп, – дип караса да, мәсьәлә һавада эленеп калды...

Ягъфәр абый тагы хакимияткә керде. Ул бит комсомол кәтәлүгендә бүртенеп, шуннан туры райком казанына сикереп, шунда кайнап, пешеп, чыныккан кеше. Колхоз чорында рәис булып чарланган карт бүре.

– Район мәдәният йорты алдында куярга рөхсәт булмаса, без аны минем йортка яки Зәки абзый йортына урнаштырачакбыз, – дигән. – Әйттек бит инде: ике һәйкәл дә бергә эшләнә. Һәм бервакытта әзер була.

– Әйдәгез алайса болай сөйләшик. Скульпторларны районга чакырыгыз. Шунда бергә утырып киңәшләшербез, – дигәннәр аңа.

– Ярар чакырырбыз. Бу бәйрәмнән соң булыр инде.

...6нчы ноябрь көнне Ягъфәр абзый белән Уфага барырга әзерләнәбез. Скульпторлар һәм кайбер кешеләр белән очрашып сөйләшәсе эшләр бар.

Әмма ул көнне безне хакимияткә сөйләшергә чакырдылар.

Ягъфәр абый белән башлык бүлмәсенә күтәреләбез. Кереп утырдык. Барчасы бер-берсен этә-төртә алгарак, түргә якынрак утырышалар. Безгә өстәлнең бу башыннан читтән генә урын калды. Башлык нигә җыелганыбызны искәртеп үтте дә, Ягъфәр абыйга сүз бирде. Абзый, гадәтенчә тыныч кына безне борчыган мәсьәлә белән хезмәткәрләрне таныштырды. Һәм дә һәйкәлне Мәдәният сарае алдына урнаштыруның никадәр мөһим булуын кат-кат исбатлады. Һәйкәлдәге хатыннарның нәкъ менә шушы урыннан юлга кузгалуларын да тасвирлады. Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү турында да, гаиләдәге тугрылык белән мәхәббәт турында да сөйләп китте.

Тик Ягъфәр абый сүзен сөйләп бетерә алмады. Һәйкәл куюга каршы кешеләр күп булып чыкты. Әле берсе, әле икенчесе, һәйкәлне Мәдәният сарае алдына урнаштыру кирәк эш түгел, дип исбатларга тырыша. Имеш, культура йортыннан чыккан кешеләргә һәйкәл арты белән торачак. Мәдәният сараеның матурлыгын каплый, имеш. Икенчесе: "Анда бит инде Чернобыль һәлакәтендә катнашучыларга обелиск бар. Нигә тагы икенчене утыртырга? Әнә иске паркның бу як очында бәдрәф кырында буш урын бар, шунда куегыз!" – ди.

Менә нинди биеклектә уйлаучылар бар бит! Өстәвенә, имеш, бу урынга күптән инде "Яшьләр аллеясы" ясарга план корган булганнар. Имеш, күптән финанс бүленгән.

Менә шулай һәйкәлне Мәдәният сарае алдына куйдырмас өчен безне бетереп ташладылар. 4нче балалар бакчасы алдындагы буш мәйданга урнаштырырга тәкъдим итәләр. Гомум фикергә килә алмыйча шулай таралыштык.

Ярар, яшәрбез, күрербез, вакыт күрсәтер! Менә шулай, Стәрлебаш авылын матурларга, районның данын тагы да арттырырга йөргән без ике мәҗнүнгә ничәмә кеше каршы чыкты. Кайчандыр икенче Бохара дип исәпләнгән Стәрлебаш һәм район таркалмасын дип көрәшкән Стәрлебаш авылы бит бу!

Киләсе атналарга Уфа скульпторларын Стәрлебашка сөйләшергә чакырырга булдык. Шунда яхшылап, безне борчыган барча мәсьәләләрне алга салып сөйләшергә килештек.

19нчы ноябрьдә Ягъфәр абый белән Уфага татарлар җыенына барабыз. Шул ук көнне скульпторлар белән дә очрашачакбыз. Сәгать иртәнге жиденче яртыларда ук торып, чәйләп алгач, юлга чыгам. Хатын инде, гадәтенчә:

– Телефоның, дару, күзлегеңне алдынмы? Документларың? – дип арттан кычкыра.

– Алдым, алдым, – дип, кесәләрне капшыйм. Барысы да урынында, кесәдә.

Иң тәүдә Мәдәният министрлыгына керәбез. Яңа гына эш башланганы күренеп тора. Хезмәткәрләр әле тегеләй, әле болай йөрештерә. Безгә кирәкле кешене сорашырабыз. 17 саны язылган бүлмәне күрсәтәләр. Ишекне шакып бүлмәгә үтәбез. Бүлмә хуҗасы безнең якташыбыз – Гөлнур Колсарина. Безне бик җылы каршы алды. Безнең белән яхшылап сөйләшеп, төрле киңәшләр бирә. Иң мөһиме – һәйкәлләрне урнаштыру-урнаштырмау турындагы карарны раслаучы комиссиягә ничек хат юлларга кирәклеген өйрәтте.

– Сез, – ди, – бу комиссиягә үзегезнең исемнән хат язгыз. Сез бит җәмәгать оешмалары. Берегез – Акмулла фонды житәкчесе. Икенчегез – районның татар җәмәгатьчелеге рәисе. Үзегезнең исемнән хат юллагыз, – дип, безгә бик акыллы киңәшләр бирде.

Зур рәхмәтләр әйтеп саубуллашабыз. Безнең юл хәзер аграр университетка. Анда якташыбыз профессор Рәфис Зыязетдинов белән очрашырга сүз куешкан идек. Рәхмәт төшкере, ул безне университет бусагасыннан ук каршы алды. Аның белән иганәчеләргә хатлар әзерләдек.

28.11.2019. Иртән үк Ягъфәр абый шылтырата:

– Онытмадыңмы? – ди.

– Юк, юк.

Ягъни бүген Стәрлебашка Лобанов Геннадий Владимирович житәкчелегендә Уфадан скульпторлар килергә тиеш.

Кунакларны каршылап, билгеләнгән вакытка хакимияткә керәбез. Башлык бик итагатьле генә барыбыз белән дә урынынннан ук торып исәнләшә. Менә сөйләшүләр башланды. Ягъфәр абый сүз башлап үзенең элекке фикерендә калуын әйтте. Моңа каршы булучылар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, янә Ягъфәр абыйга каршы сөйли башлады.

Шуннан Геннадий Викторович:

– Бу монументаль һәм мәдәни скульптураның урыны тик район Мәдәният сарае алдында гына. Без бит сезгә чаклы булган башлык белән сөйләшеп, һәйкәл урынын тәүдә ук килешкән идек. Мәдәният сарае директоры Рафаил Йосыпов та риза иде, – диде.

Шунда берәү:

– Вот, допустим, мин карават ясаучы ди. Һәм караватны ясап саттым, ди. Алган кеше карават-

ка хуҗа. Шулай булгач, караватны хуҗа кайда тели, шунда куя. Бу сезнең арт-объектыгызны да район кайда тели, шунда куярга хаклы, – дип, үзенең тозсыз сүзләрен әйтеп ташламасынмы?!

Уфа кунаклары аның авызын тиз япты:

– Бу тегенди-мондый арт-объект түгел, ә монументаль һәйкәл!

Мин дә сүз кыстырып әйтүне кулай күрдем. Һәм барчасына да карап алдым да:

– Салават Юлаев һәйкәлен дагстанлы осетин Тавасиев дигән кеше ясаган. Скульптура обком каршында гына булачак, шунда куябыз, дигән карар кабул ителә. Ә Тавасиев, бу урынга риза булмыйча, берничә көн Уфа тирәли җәяү йөреп, үзе Салават Юлаев һәйкәленә урын эзли. Һәм менә әлеге урынны сайлый.

Тавасиев болай ди:

– Мин сайлаган урынга куярга теләмисез икән, батырыгызга һәйкәл дә булмый. Бүтән урынга мин риза түгел, – ди.

Күреп торасыз, Салават батыр һәйкәле Уфага нинди ямь, күркәмлек биреп тора. Шуңа да һәрнәрсәнең үз урыны булырга тиеш! – дим.

Тагы кызып-кызып фикер алышулар башланды. Башлык, сәгатенә карап алды да:

– Мин район халкының икегә бүленеп бер-берсенә каршы көрәшүен теләмим. Шулай булгач, нык-лап уйлашыйк! – дип, утырышны тәгәлләде.

...Менә без ничәнче тапкыр урыннар карарга чыктык. Бер ханым безгә мәйданчыклар күрсәтеп йөри. "Магнит" кибете каршындагы әфганчыларга куелган һәйкәл артын күрсәтә. Әмма артында урнашкан бина ярымҗимерек хәлдә. Геройлар аллеясына куярга дигән тәкъдим дә уфалыларның күңеленә хуш килмәде. Аннан инде Пенсия фонды алдыннан урын күрсәттеләр.

Лобанов тиз уйлап фикер йөртүче кеше икән.

– Пенсионный фонд икәне күренеп тора. Интернетка куячаклар. Пенсия аз булгач, авыл хатыннары пенсия артыннан арба тартып Мәскәүгә китеп бара, диячәкләр. Икенчедән бу тар урынга нәрсәгә тыкшындырырга? – дигәч, барча халык елмаеп-көлеп җибәрде. Бу урын үзеннән-үзе төшеп калды.

Хәзер паркка килдек. Әмма скульпторлар бердәм бу урынга каршы булды. Бик тә кысынкы урын. Бәдрәф кыры. Бу да барып чыкмады. Киттек яңа төзеләчәк парк җирен карарга. Аны Мөхәммәтшакир Тукаев һәйкәленә туры килә торган урын дип таптылар.

Шуннан инде Ягъфәр абый, ачынып, йөрәгеннән:

– Район Мәдәният сарае алдында булмый икән, спонсорлар акча бирмәячәк. Шулай булгач, Стәрлебашның бренды булырлык һәйкәл Стәрлебашка кирәкми булып чыга. Юк тек, юк инде! Черномырдин әйткәнчә: "Яхшы булсын дип эшлисең, тырышасың, ә һәрвакыттагыча килә дә чыга!"

Мин дә, әрнеп:

– Ярар, Ягъфәр абзый, бик кайгырма. Кичә Казаннан шылтыраттылар. Алар һәйкәлне үзләренә сатуны сорый. Оренбурглар да кызыксына. Шуларга сатарбыз да, акчаларын спонсорларга кайтарып бирербез, – дим, барысы да ишетерлек итеп. Андый уй-фикерләр дә башка керә башлаган иде.

Шулай таралыштык. Ягъфәр абыйларга алып барып, кунакларны төшке аш белән сыйлыйбыз. Аның хатыны Римма апага рәхмәт! Татар хатыннарына хас булганча, табынга бик тә тәмле-тәмле ризыклар пешереп, мул табын белән безне елмаеп-көлеп каршы ала. Төшке аштан соң кунакларны Уфага озатып җибәрдек. Мин өйгә кайтып киттем.

Ярты юлда Ягъфәр абый шылтырата:

– Башлык бүген кичке сәгать алтыга үзенә чакыра. Килә аласыңмы?

– Әлбәттә, киләм.

Җитәкче безне елмаеп каршы алды. Һәм сүз башлады:

– Сез башлап йөргән эш бик яхшы эш инде. Әмма менә каршы килүчеләр дә бик күп җыелды бит. Әйдәгез әле яңадан тынычлап кына сөйләшик. Әйтик, менә киләсе елга балаларга сәнгать мәктәбе төзергә планлаштырабыз. Шул сәнгать мәктәбе алдына урнаштырсак, ничек була? СОК (Спорт-сәламәтләндерү комплексы) алдына куйсак та начар булмас, дип уйлыйм. Анда ошамаса, менә элекке поликлиниканы фатирлар итеп яңартачакбыз. Шуның алдына, я булмаса, 1нче мәктәп артында булса, ничек уйлыйсыз?

Ягъфәр абый белән алдыбызда яткан Стәрлебаш авылының архитектур планнарын карыйбыз.

– Алдан ук бу вариантларны безгә берсе дә әйтмәде бит. Без бит элеккеге башлык һәм Мәдәният сарае директоры белән сөйләшеп килешкәч кенә спонсорларга финанслау турында мөрәҗәгать иттек. Алар да Мәдәният сарае каршына куйсагыз, акча була, бик матур, дөрес сайланган урын, диделәр. Аннан да бигрәк, хатыннар нәкъ менә шушы урам башыннан кузгалган. Элек бу урында урам иде. Мәдәният сарае төзер өчен өйләрне күчереп, урамны үзгәрттеләр.

Рөстәм Камил улы:

– Сез инде алай ук "юк" дип кырт кисмәгез. Һәйкәл бик яхшы нәрсә. Шуңа күрә ашыкмыйк әле. Тагы бер кат уйлашырбыз, – ди.

Әңгәмә барышында сиземлибез: аның фикере безнең якка үзгәргән. Шулайрак шул. Күрәсең, урындагы халык бу ике тискәрене тыңлый һәм аларны яклый, дигән уйга килде.

Бик мәслихәт кенә, куллар кысышып аерылыштык. Бу безнең яктан бәләкәй генә җиңүгә таба ярты адымыбыз иде. Ничек кенә булмасын, яхшы якка ярты адым. Һәм безнең кәефләр күтәренке. Абзый белән хушлашып, өйгә кайтырга кузгалдым. Һич кенә дә аңламыйм: нигә кайбер кешеләр һәйкәлне клуб алдына куярга каршы килә соң? Уйлап-уйлап та очына чыгарлык түгел.

2019 елның 6нчы декабрендә Уфага юл алдык. Таң белән кузгалдык. Юл ачык булса да, көчле җил исә. Аннан да бигрәк, томан төсле вак кына яңгыр машина тәрәзәсенә ябышып, боз булып туңа. Шундый кыенлыклар белән Уфага якынлашабыз.

Туп-туры Хөкүмәт йортына барабыз. Машинаны куярга көчкә урын табып, җәяүләп килдек. Пропуск алулары бик озакка сузылды. Гөлназ Нургалиева дигән ханым белән барысын да алга салып сөйләштек. Ул сораша, без сөйлибез. Бу эшкә скульптор Г. В. Лобанов та катнашканын белгәч:

– Геннадий Викторовичка әйтегез: һәйкәлне Мәдәният сарае алдына куярга кирәклеген дәлилләп, Башкортстан Рәссамнары берлегеннән хат әзерләп, безгә китерсеннәр. Никадәр тизрәк, шулкадәр яхшырак булыр. Бу комиссиянең берничә утырышы булды инде. Шулай да быелгы соңгы утырыш 20нче декабрьләрдә булуы ихтимал. Быел булмаса, киләсе елның гыйнвар айларында булыр, – дип, безгә яхшы-яхшы киңәшләрен бирде.

Кәефләребез яхшырганнан-ях-



*Сулдан уңга:* ***Ягъфәр Хисмәтуллин, Хисаметдин Исмәгыйлев һәм Стәрлебаш авыл Советының бүгенге башлыгы Фәргать Фаткуллин.***

шыра. Безнең белән бер теләктә булган кешеләр Уфаның үзендә дә бар икән. Безне озата төште. Шунда:

– Абзыйлар, күреп торам, бик актив кешеләр икәнсез. Шуңа да мондый җәмәгать эшләренә яшьләрне дә үзегезнең арттан ияртү кирәк, – ди.

Без аның тәкъдим-фикерләре белән килешәбез. Куллар кысышып аерылышабыз.

17.02.2020. Үткән атнаны ук район башлыгына керергә язылдык. Бүген сәгать өченче яртыда кабул итә башлый, диделәр. Хакимияткә килдек. Рахмангулов безне бик җылы кабул итте. Кәефе әйбәт күренә. Без инде әлеге шул һәйкәл турында сөйләшергә дип кердек. Безнең кулда мәдәният министрының хаты да бар. Ул хатта "министрлык һәйкәл куюга каршы түгел. Әмма бу мәсьәлә район карамагында", – диелгән.

Башлык:

– Бу турыда үзем дә күп уйладым. Менә сез башка урынга куярга риза түгелсез бит. Шуңа да уйлый торгач, мондый нәтиҗәгә килдем. Мәдәният сарае алдындагы "Чернобыльчеләр" мемориалы кырына куйсак, ничек булыр? – ди. Һәм кәгазьдә урынын сызып күрсәтә. Шушында ук "Чернобыльчеләр" мемориалын башка урынга күчерергә вәгъдә бирә. Мин инде бу вариантны кабул итәм. Һәм риза икәнемне белдерәм. Ягъфәр абый гына, икеләнеп, бик үк риза булмаганлыгын җиткерде. Эчтән генә уйлыйм: иң мөһиме һәйкәлне клуб алдына урнаштыруга ризалык алырга кирәк. Ризалык алып, кәгазь эшләре беткәч, аны тегеләйрәк, я булмаса, болайрак урнаштырып булачак бит. Һәйкәлне шушы урынга урнаштыруга язма рөхсәт булсын. Депутатлар сессиядә карап, карар кабул итсен. Шул карар белән безгә алдагы эшләрне башкарырга җиңелрәк булачак. Сынчылар да эшкә тотыныр. Коючылар да әзерлектә булачак. Аннан, акча белән тәэмин итүче спонсорлар белән сөйләшүләр алып барырга да җиңелгә туры киләчәк. Кулда депутатларның карары бар бит. Шуларны уйлап, бу вариантка мин куш куллап ризалыгымны белдерәм. Бераз икеләнгәч, Ягъфәр абый да ризалаша.

Шулай сөйләшеп, бу мәсьәләне чәршәмбе депутатлар советында карарга булдылар. Бу көн бик уңышлы үтте дип, Ягъфәр абый белән балаларча шатланышып өйләребезгә юл алабыз.

Менә җәмәгать тыңлауларында бу мәсьәләне тикшереп утырабыз. Бу киңәшмәдә Мәдәният сарае алдына һәйкәлне кую өчен Стәрлебаш авыл хакимиятенә мөрәҗәгать итәргә кирәклеген әйттеләр.

Икенче көнне, Ягъфәр абзый белән икәүләп, Стәрлебаш авыл хакимиятенә мөрәҗәгать язып алып килдек. Ә башлык шушы көнне ялга китә икән, аннары башка эшкә күчәчәк, дигән хәбәрләр дә ишетелә башлады. Шулай итеп, безнең эш тагы билгесез вакытка һавада эленеп калды. Ул да түгел, коронавирус эпидемиясе килеп чыкты.

Ниһаять, Стәрлебаш авылының яңа гына тәгаенләнгән хакимият башлыгы Азамат Галиев безгә, һәйкәлгә урын тәгаенләү турында халык тыңлаулары 7 майда үтәчәк, шул көнне килерсез, дип әйтте.

Менә билгеләнгән көнне авыл хакимиятенә килеп кердек. Авыл хакимияте башлыгы белән бергәләп Мәдәният сарае алдын яңадан карап чыктык. Аннан бүлмәсенә керәбез. Мин һаман эшнең уңышлы барып чыгуына шикләнеп утырам. Тагы бер-ике хезмәткәр керде. "41нең арбалы хатыннары" пьесасындагы хатыннарның кызлары Хәлимә белән Зәкия килде. Җәмәгать тыңлаулары башланды. Безнең мөрәҗәгатьне укып ишеттерделәр.

– Һәйкәлне Мәдәният сарае алдына урнаштырырга кемнәр риза? Кулларыгызны күтәрегез! Каршылар? Юк. Бертавыштан кабул ителде.

Бу тыңлауларда барлыгы җиде кеше булдык. Мәсьәлә шулай гади генә, үзеннән-үзе уңай чишелде дә куйды.

Тышта яз! Безнең күңелләрдә кояш балкый! Мең-мең рәхмәтләрне әйтеп урамга чыгабыз. Шатлыктан кычкырып җырлыйсылар, биеп җибәрәсе килә. Ягъфәр абыйларга киттек. Шатлыклы хәбәрне Римма апага да җиткерәбез. Ул да елмая. Шунда ук Уфадагы скульпторларга да шылтыратып, шатлыгыбыз белән уртаклашабыз!

Аларны тагы чакырып, тирә-якка ничегрәк килештереп, яраклаштыру турында сөйләшергә туры килде. Аларча, ягъни уфаларча әйтсәк, бу архитектур дизайн дигән нәрсә икән. Скульпторлар үзгәрешкә бик үк риза булмаса да, нишләсен инде, килеште. Әлеге шул түбән, почта ягына караган өлешен югары күтәреп тигезләргә кирәк булачак. Бу инде безнең кассадагы барлы-юклы финанска көчергәнеш тудырачак. Нигез кыйммәтләнеп катлауланачак. Шуннан инде Чернобыльчеләргә куелган мемориаль корылманы да күчерергә кирәк булачак. Аны күчерүне безгә йөкләтергә тырыштылар.

Әлеге шул мең мәшәкатьләр белән җәй үтеп бара. Ул печән, ул бәрәңге дигәндәй. Ягъфәр абый белән ике тапкыр Красноуфимск шәһәренә барып кайттык. Скульптор егет Мөхәммәтшакир Тукаев сынын балчыктан эшләп бетергән. Кайбер кимчелекләрен дә әйттек, төзәтте. Һәйкәлнең йөзен Мөхәммәтшакирның берданбер фотосы белән чагыштырган идек, аерып алгысыз. Киемнәрен Зөлфия Гыйзетдинова язган "Давыллы еллар" пьесасындагыча итеп эшләде.

Бүген 16нчы ноябрь, 2020 ел. Ягъфәр абый кичтән үк шылтыратып куйды:

– Хисами, иртәгә Красноуфимскидан коючылар Мөхәммәтшакир Тукаевның һәйкәлен алып килә, онытмадыңмы?

Онытам буламы соң! Мин һәрвакыт әзер. Пионерлар кебек. Әле менә Стәрлебаш авыл хакимиятенә мөрәҗәгать язып утырам. Тукаев һәйкәле куеласы урынны ачыклау өчен. Ике урын. Берсе – "Яшьләр" паркының уртасы. Икенчесе – нәкъ Карл Маркс урамы башланган урын, Нил абый Рәмиев җитәкләгән зур мәчет ихатасының

сул ягы. (Әйткәндәй, Нил абзый – шагыйрь Рәмиевлар нәселенең туры дәвамчысы. Шәҗәрәсе дә бар. Тамырлары Муса Җәлилне дә үз эченә ала.) Әмма җәмәгать тыңлауларында Стәрлебаш халкы ни әйтер? Кайсы урынны сайларлар?

Каһәр суккан пандемия аркасында җыелып сөйләшүләр мөмкин түгел. Барча тәкъдим һәм кире кагулар телефон һәм Интернет аша гына булачак. Ул ничек үтәр? Күз алдына китерүе кыен. Гомумән, онлайн дигән тыңлауларга халык катнашырмы?

Тәтербаш авылына җитәрәк, Ягъфәр абый шылтырата:

– Кунаклар ярты сәгатьтән килеп җитәбез, диләр. Син кайда?

– Мин Тәтербашка җиттем инде.

– Алайса, аларны юл бөҗрасында көтеп, каршы ала тор, – ди.

Шулай килештек. Әмма кунаклар билгеләнгән вакыттан күпкә алданрак килгән икән. Мин бөҗрада Стәрлетамак юлын күзәтеп утырам, ә алар юк. Тагы абзый шылтырата:

– Кунаклар килеп җитте. Син кайда?

– Бәй, мин аларны монда көтеп утырам.

– Тиз генә Гаскәров Римнең складкибетенә, элеккеге “Кислород”ка килеп җит, – ди.

Мин “Кислород”ка барып җитүгә, Ягъфәр абый да кунакларны ияртеп килеп җитте. Ул, тыны кабып:

– Банкка ашыгам. Һәйкәлне шушында бушатып, склад эченә кертеп урнаштырыгыз, – диде дә китеп барды.

Күп тә үтми, безгә һәрчак ярдәмләшеп килгән милли аңлы, татар җанлы Фәрит Искәндәров килеп җитте. Алай гына да түгел, үзе белән инде нык картайган Зәки абзыйны да алып килгән. Аллаһка шөкер! Зәки аганың күптәнге хыялы тормышка ашты, дияргә була. Аның хәтта күзләреннән яшь тә чыкты шикелле. Әллә миңа гына шулай күренде ме? Абзый кешеләр алдында яшь күрсәтеп тора торган шәхесме? Юк инде. Халкыбыз әйтмешли, авызы тулы кан булса да, кеше алдында түкермәс. Менә шундыйрак инде ул безнең Зәки абзабыз.

Тиз арада электросеть оешмасында эшләгән егетләргә әйтеп, Гаскәров Римнең улы Илнур һәм тагы берничә егет, һәйкәлне бик җиңел генә бушатып, складка урнаштырдык. Ягъфәр абый хәтта һәйкәл өстенә ябарга материал да алып килгән булып чыкты. Һәйкәлне шул материал белән әйбәтләп төреп тә куйдык. Зәки аганың безгә әйткән сүзләре әле дә хәтердә:

– Аллаһыга шөкер, Мөхәммәтшакирның һәйкәлен күрергә Ходай насыйп итте. Әйттем бит мин сезгә, егетләр, сез икәүләп тотынсагыз, барысын да булдырасыз дип. Карагыз әле, нинди зур эш эшләдегез. Инде хәзер яхшылап урынына да куярсыз, дип ышанам. Ходай насыйп итеп, “41нең арбалы хатыннары”н да башкарып чыгарсыз. Инша Аллаһ, шулай булырга язсын! Бу эшләрегез Стәрлебаш тарихында гына түгел, барча Башкортстан тарихында үрнәккә лаек эш!

Бергәләшеп иске-яңа урыннарны карарга чыктык. Карадык, күрдек. Кунакларга яңа парктагы 4нче балалар бакчасы каршындагы һәм Карл Маркс урамы башланган урыннар ошады. Коючылар һәм скульпторлар да шушы урыннарны яраклы дип әйткән иде бит.

Мөхәммәтшакир Тукаевның һәйкәлен яңа төзелеп яткан “Яшьләр” паркына урнаштырырга сөйләшенеп-килешенгән иде. Урынын да билгеләдек. Нәкъ уртасында булачак. Бу урын барыбызга да ошады.

Парк төзелеп бетте. Ниһаять, 30 ноябрьдә паркны ачтылар. Яшьләр паркын дәүләт комиссиясе кабул иткәннең икенче көнендә үк, башлык урынбасарына керәбез. Һәйкәлнең постаментын килешенгән урынга төзи башлау турында рөхсәт сорыйбыз. Рөхсәт бирелде. Тик мине ниндидер билгесез шик кимерә. Бик тә гаҗәп, тиз һәм тоткарлыксыз башкарыла бу эш, дип уйлыйм.

Чынлап та, паркта постамент эшләнеп бетүгә һәйкәлне икенче урынга урнаштыру турында фәрман килде. Әмма каршылыклардан безнең рухыбыз гына ныгый, көчебез һәм үҗәтлегебез икеләтә арта. Әйтеп торам бит, бер-ике көннән яңа көч, яңа дәрт белән эшкә тотыначакбыз.

“Арбалы хатыннар” һәйкәлен дә эшләтеп бетерәсе бар. Акча ягы чамалырак булганнан, әле бер, әле икенче эшкуарга мөрәҗәгать итеп карыйбыз. Берсе, акчасы юклыкка зарланып: “Уфа шәһәреннән яңа гына фатир алдым, шуңа ипотека түлим”, – диде. Икенчесенә барып баш иябез. Ул, ничектер, безгә өстән генә карап һәм мыек астыннан гына елмаеп:

– Абзыйлар, бу турыда уйларга кирәк. Уйларбыз, – диде.



Язучы Зәки Зәйнуллин.




Мөхәммәтшакир Тукаев һәйкәле.



Зәки Зәйнуллинның үз кулы белән ясалган макет районның төбәкне өйрәнү музее җитәкчесе Зөлхиҗә Әсәдуллинага тапшырылды.



*Сулдан уңга:* ***Стәрлебаш районы хакимияте башлыгы Рөстәм Рахмангулов һәм Зәки Зәйнуллинның тормыш иптәше Суфия, балдызы Хәлимә апалар.***

Бер ун көннән тагы барган идек, ул тагы:

– Әле уйлыйм, – дию белән генә чикләнде. Сүз бетте, дигәнне аңлатып, телефоннан кемгәдер шылтырата башлады.

Аптыраган, җитешеп бетмәгән финансны кайдан табарга? Ни булса да була дип, Ишембайдагы "Витязь" заводының генеральный директоры белән сөйләшергә булдым. Ул да якташ бит, ләкин бездән күпкә яшь, үзен бик белеп тә бетермибез. Әмма әти-әниләре әйбәт кешеләр иде. Нишлисең бит, нужа печән ашата, диләр. Ул егетнең ярдәм итәчәгенә бик ышанып бетмичә генә телефоннан шылтыратам.

– Безгә очрашып сөйләшеп алырга кирәк иде. Күп дигәндә биш минут булыр. Авылга кайчан кайтасыз?

– Шушы атнаның азагы, шимбә көн булыр. Шунда очрашырбыз.

Түземсезлек белән атна азагын көтәм. Ирек Наил улы кайтасы көнне сәгать унберләр тирәсендә аңа шылтыратам. Юк, авылга кайтмаган икән. Кичкә генә кайтам, үзем шылтыратырмын, ди. Көне буе көтәм. Караңгы да төште. Кышкы көн кыска бит. Шулчак телефоным шылтырый.

– Бу Ирек иде. Мин Стәрлебаш юлындагы божрага килеп җиттем. Киоск кырына чыгып торыгыз. Шунда очрашырбыз.

Шунда ук Ягъфәр абыйга хәбәр итәм. Хәлне аңлатып бирдем. Тизрәк очрашасы урынга килеп җитүен үтендем. Көн салкын һәм җиле дә бар. Ирек белән исәнләшәм. Мин инде ярышка чыккан ат шикелле, тиз-тиз хәлне аңлатып бирдем. Фара яктысында булачак һәйкәл модельләренең фотосын да күрсәтеп, кыскача гына аңлатмалар да бирәм. Һәм турыдан-туры:

– Бу эшләргә шулкадәрле акчабыз җитеп бетми. Мөмкин булса, бер миллион сумга ярдәм итә алмассыз микән? – дим.

– Абзый, без Мәскәүгә бәйле кешеләр. Шуңа да завод ярдәм күрсәтә алмый. Ярдәм күрсәткән очракта да, эше бик озакка сузылачак. Булса, үземнең кесәдән чыгарып кына бирергә була. Бу турыда уйларга вакыт бирегез. Киләсе атнага үзем шылтыратырмын.

Менә Ягъфәр абый да килеп җитте. Һәйкәл урнаштырылачак урыннар турында сөйләшеп алдык. Очрашу менә шулай, тиз-тиз, юл өстендә генә үтте.

Берничә көннән Ирек Наил улы яңадан элемтәгә чыкты:

– Мин сезнең тәкъдимегезне кабул итәм. Тик ярдәмем киләсе елның гыйнвар аенда гына булыр, – ди.

Менә шундый сөйләшү булды. Мин күңелем белән күкләргә күтәреләм. Шунда ук Ягъфәр абзыйга шатлыгымны җиткерәм.

***

Менә яңа ел да үтте. Алдан вәгъдәләшкәнчә, Зәки аганың хатыны Суфия апа белән очрашуга килдем. Очрашу Суфия апаның сеңлесе Хәлимәләр йортында булды. Өч сәгатькә якын сөйләшеп утырдык. Апа бик күп нәрсәләр сөйләде. Әлеге шул Стәрлебаш хатыннарының ирләре янына киткәнен күргән бердәнбер тере шаһит.

– Ул чакта миңа сигез яшь иде, – дип, апа сүзен башлады. – Әйе, ул чакта миңа сигез яшь иде. Сугыш чыккан, диләр. Юньләп аңламыйм да әле. Теге оч малайлары белән бу оч малайлары сугыштылар микән, дип уйлыйм. Әниләрнең һәм күрше апаларның хафаланып сөйләшкәнен, ниндидер каһәр суккан Герман тагы безгә карата сугыш белән кергән икән, дигән сүзләрне ишетәм. Бу хәбәрне бездән өске якта яшәгән Заһидә апа кычкырып, сөрән салып дигәндәй, барча урамга таратты. Хәтеремдә без әтиәниләр белән чәйләп утырган чак кебек тә калган. Әти:

– Тукта әле, белеп кайтыйм, нинди сугыш ди ул? – дип, урамга чыгып китте. Йортка бик тә кәефе бетеп кайтты. Әйберләрне, үзенең эш коралларын җыештыра башлады. Авылда берничә кешедә генә вилсәпид дигән нәрсә бар иде. Ул да бездә бар. Шуны келәткә кертеп биеккә элеп куйды. Сугыш башлангач, авыл бөтенләй тынып калган кебек булды. Югары очта кайчакларны кичләрен моңлы итеп яңгыраган гармун тавышы да ишетелми башлады.

...Менә әтиләргә дә китәргә чират җитте. Әни Мансур энемне кулына күтәргән, мине әти җитәкләде. Әти, әнигә карамый гына:

– Лар тулы иген. Бик мулдан тотынмый гына ашасагыз, хәтсезгә җитәргә тиеш. Бу сугыш озакка бармаска тиеш. Ил бит хәзер көчле. Озакламый кайтып та җитәрбез. Дөнья хәлен белеп булмый, шулай да туганнар белән бергә яшәп, балаларны сакларга тырыш, – ди. Әни бертуктаусыз яшен коеп, әледәнәле күзләрен сөртә.

Кешеләр күмәкләшеп җыелган урынга килеп җиттек. Үзем укырга төшкәч белдем: бу урын татар мәктәбе алды иде. Мин белмәгән абый-апалар бик күп җыелган. Читтә җигүле атлар да тора. Бер як

кырга барып бастык. Әле иртә булуга карамастан, күктә кояш кыздыра. Ул арада булмый, безнең кырга әнинең сеңлесе Мәһиәсма апа белән Мәҗит җизни килеп бастылар. Мәһиәсма апа олы корсагы белән җизнигә сыенып басып тора. Елаудан күзләре кызарып беткән. Менә: “Тезелергә!” – дип кычкырдылар. Җыелган халык “гү” килеп алды да, тынып калды. Бик көчле тавышлы бер хәрби кыска гына нотык тотты. Аннан, арбаларга утырырга, дигән тавыш ишетелде. Җыелган халык, уллары, әти-абыйлары белән саубуллаша башлады. Хатын-кызлар яңадан елашырга тотынды. Бездән якында гына бер апа ике кулына игезәк балаларын күтәреп басып тора иде. Ул да кычкырып елый. Әни белән Мәһиәсма апа алай бик кычкырмыйча гына лышык-лышык киләләр. Аларның елаганын күреп, мин дә елап җибәрдем. Әни, кулдан тарта биреп:

– Берүк, балам, кычкырып елап, әтиең күңеленә шом салма! – дип, пышылдый. – Әтиеңә ансыз да кыен бит. Аның исән-сау кайтуын гына телә, – ди.

Мин барысын да бик аңлап та бетмим әле. Шулай да:

– Әти, әти, тизрәк кайтыгыз! – дип кычкырам.

Әтиләр утырган арбалар кузгалып китте. Апалар озак кына арбалар кырыннан ияреп барды. Авыл бөтенләй бушап калды. Хәзер күктәге кояш та алай бик кыздырмый, безне җәлләп кенә, моңсуланып яктылыгын сибә төсле иде.

Әни-апаларның йөзеннән елмаю качты. Элек балалар чыр-чуыннан шау-гөр килеп торган урам ничектер ятимсерәп калган төсле. Әниләр көн дә таң белән колхозга эшкә йөгерә. Мансур энемне карау минем өскә йөкләтелде. Садрикамал картәни көн дә безгә килеп хәлебезне белеп китә. Кайбер көнне Мансур энемне күтәреп мин аларга баргалыйм. Картәни безгә тәмле итеп төче күмәчләр белән каймаклап чәй эчерә. Әниләр кайтмас борын ук өйгә кайтабыз. Чөнки көтүдән сыерны, сарык-кәҗәләрне каршы алырга кирәк. Алар да минем өстә. Менә шулай яши башладык. Тормыш бөтенләй үзгәреп, без, шул еллардагы балалар, вакытыннан алда олыгаеп, тормыш арбасына төптән җигелдек.

Беркөнне Мәһиәсма апа кичләтеп кенә килеп әнигә әтиләрнең Раевка стансасында ач ятканнарын әйтте. Күп тә үтми иптәш хатыны килеп җитте. Алар әни белән икәүләшеп тагы кемнәргәдер чыгып китте. Икенче көнне картәти белән картәни дә безгә килеп озак кына ах та ух килеп сөйләшеп утырды. Әниләр әтиләр янына барырга бригадирдан ат сораган булган. Ул:

– Барча ару атларны сугышка алып киттеләр, – дигән.

Мин аптырыйм. Ничек инде атларны да сугышка алсыннар ди? Атлар сугыша беләме дә, мылтык тотып йөгерә беләме, дип уйлыйм. Үсә төшкәч кенә аңладым: юкка гына “ир-ат” димәгәннәр бит. Атларның да ирләр белән язмышлары уртак икән шул. Шулай итеп, атлар да сугышка китте. Аларны да сугышка алдылар.

Гобәйдулла картәти тәкъдиме белән әниләр Хәмит абый ясаган “фурман” дигән арбаны тартып барырга булдылар. Хәмит абый ул арбаны яшь ярымлык тайны җигәргә өйрәтү өчен, шулай бәләкәй генә итеп ясаган икән. Халык яшь тайларны җигәргә өйрәтә башлады бит. Алар да, без, сугыш елгы балалары кебек, бик иртә, вакытыннан алда тәртә арасына керде.

Әниләр таң атмас борын ук юлга кузгалырга сөйләште. Кара таңнан картәни белән без капка алдына чыгып озатып калдык. Алар шул арбаны тартып, нәкъ менә әлеге Мәдәният сарае урнашкан урыннан кузгалып китте. Элек урам шул урыннан башлана иде. Мәдәният сарае салыр өчен андагы өйләрне күчереп, ул урынны зурайттылар. Шуннан гына клуб салдылар. Картәни догалар укып әниләрне озатып калды. Мин дә картәнигә кушылып битемне сыпырам.

Алар бер атна дигәндәме (төгәл генә хәтерләмим) арып-талып кайтып җитте. Әнинең генә бәхете җиңгән. Әти белән бер көн бергә була алганнар. Әни үзе поездга утыртып әтине озату бәхетенә ирешкән. Башка апаларның ирләрен бер тәүлек алда гына фронтка озаткан булганнар. И-и үкенечле булды аларга, дип, әни уфтанып сөйләде.

Беренче сентябрь көнне күп кенә дус кызларым мәктәпкә киттеләр. Минем дә барасы килә бит, әй. Елапелап, әнидән мәктәпкә җибәрүен сорыйм. Юк, җибәрми. Туганың Мансурны кем карый, ди. Кызларга ияреп, барыбер мәктәпкә бардым. Әни арттан алырга килгән. Шунда укытучы Мәрхәбә апага рәхмәт инде. Ул, әнине тынычландырып: “Йөрсен. Бераз йөргәч, арып-туеп үзе ташлар әле. Әлегә йөреп торсын”, – диде. Шулай мәктәпкә йөреп киттем. Кайда ди ул мәктәптән тую! Анда кызык, балалар күп. Төрле уеннар уйныйбыз. Укырга-язарга тиз өйрәндем. Хәтта әтигә хатларны үзем яза башладым. Күрше кызлары кебек чәчәкләр төшереп бизим дә әле. Хәтеремдә, әтигә бер хат язганымда, әти, миңа сумка алып кайт, дип язганым да булды.

Ә Зәки белән бер сыйныфта укыдык. Бәләкәй генә буйлы, сипкелле, җирәнрәк малай иде. Физкультура дәресендә сафка тезелгәндә дә миннән артта була торган иде. Олы сыйныфларда буйга үсеп, мине узып китте.

Икенче язны безнең ак башлы сыерны бригадир көтүгә кудырмады. Колхозга алып сабанга җиктеләр. Бер-ике көн җәфалап йөрткәч, сабан тартып йөрергә дә өйрәнгән, бахыр сыер. Сөтен савып эчү генә җитмәгән, сабан да сөрсен инде. Ул сугыш дигән каһәр суккыры нәрсәнең авырлыгы кешеләргә генә түгел, йорт хайваннарына да төште. Сыерлар да, кешеләр кебек, сугыш авырлыкларын үз җилкәләрендә өстерәде. Тракторлар юк, атлар җитешми. Хатыннар елый-елый шул сыерлар белән басуда сабан сөрде. Үзләре җигелеп тырма тарттылар.

Ул чакларда урамда почта апасы күренсә, дер калтырап тора торган идек. Бу тагы нинди начар хәбәр китерер икән дип. Чөнки күпләрнең әтиләреннән кара хәбәр – похоронкалар килә башлады. Аллаһыга шөкер, безнең әтидән андый хәбәр килмәде. Әти өч тапкыр яралана. Азаккы яралануында эшелон белән кайдадыр Себер якларына озаталар. Дим стансасында паровозга су тутырганда махсус төшеп кала. Шуннан аны Уфадагы бер госпитальгә урнаштыралар. Берчакны авылга, Хәйбулла кайта икән, дигән хәбәр таралды. Капка алдына халык җыелды. Көтәбез. Әти урам башыннан култык таякларына таянган килеш чатанлап кайтып килә. Мин түзмәдем, әтигә каршы торып йөгердем. Арттан башкалар да килеп җитте. Әтинең бер аягы салынып тора. Бау белән муенына аскан. Мансур гына читтә ятсыныбрак тора. Чөнки әтине хәтерләми дә. Шулай да мин әтине кочаклап алгач, ул да якын килде. Әти ничек

итсә итте, туганымны күтәреп ала алды. Ул көнне бездә бәйрәм булды. Бу 1943 елның җәе иде.

Әтинең сөйләве буенча госпитальдә әтинең аягын кисәргә уйлаганнар. Нindидер табиб кереп, кистермәгән. Аңа әтием гомер буе рәхмәтле булды. Теге доктор әйткән: "Ничава, татарин, тагы биш еллап җәфаланырсың инде. Әмма җайлап аягыңа да басып йөри башларсың әле", – дигән. Чынлап та, әти биш елдан соң аягына әзәзләп булса да басып йөри башлады. Аңа чаклы Абдрахман бабай (бик оста иде) ясап биргән агач аяк белән йөрде.

Аягы авырткач, әти авыр эшкә ярамый. Ә колхозда җиңел эш бармы соң? Юк бит ул. Кәнсәләрдә уйлашканнар да колхоз умарталыгына умартачы итеп тәгаенләделәр. Барлыгы биш баш умарта калган. Әти шул умарталыкта эшли башлады. Умарталык ерак, Урман авылында. Эшкә йөрергә бер бәләкәй генә, җигүгә өйрәтелгән тай бирделәр. Шуның белән умарталыкка эшкә йөри. Әти шул җәйне үк умарталарның санын бераз арттыруга ирешә. Әти рамнарны, умарта савытларын да үзе ясый иде, мәрхүм.

* * *

Кич сәгать бишләр тирәсендә Ирек шылтырата:

– Хисаметдин абый, мин Стәрлебашка керә торган юл боҗрасын үттем. Урамдагы киоск алдында көтегез. Шунда очрашырбыз.

– Яхшы. Көтәм.

Тиз киенеп, машинамны кабыздым да билгеләнгән урынга төшеп киттем. Менә озак та көттерми Ирек тә килеп җитте.

– Менә абзый, вәгъдәләшкәнчә әйткән сумманы алыгыз, – дип, кулыма бәләкәй генә төргәк тоттыра.

Мин үз чиратымда:

– Расписка биримме? – дип сорыйм.

– Нинди расписка ди ул? Сез нәрсә?

– Акча алганга.

– Юк инде. Бу бит үземнең хәләл, шәхси акчам. Мин сезгә ышанам, абзый, шулай булгач, расписка турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Шул башлаган эшләрегезне уңышлы тәмамлап чыгарга язсын.

– Иншаллаһ, шулай булсын! Сезгә Ходай исәнлек-саулык бирсен. Шушы изге эшебезгә сарыф иткән акчагыз уны белән кире кесәгезгә кайтсын. Ходай насыйп итеп, шушы теләкләребез тормышка ашсын!

Ирек китте. Мин киоск алдында бер мизгел машина эчендә уйланып торам. Бу кадәрле акчаны кулыңа тоттырсыннар әле. Чынлап торып безнең эшләр изге шул. Шул турыда уйлап алдым да, туры Стәрлебашка Ягъфәр абыйларга киттем.

Абзый өйдә иде. Тик бер дә кәефе юк.

– Нәрсә булды, Ягъфәр абзый?

– Апаңны ясалма сулыш алдыру аппаратына урнаштырганнар. Хәле бик шәптән түгел.

Шулай бераз гына хәл-әхвәл сорашкач, теге төргәкне өстәлгә куеп:

– Менә, Ирек акча калдырып китте. Хәтта расписка да алмады.

– Сүзендә нык тора торган кеше икән. Молодец, афәрин! Әтисе кебек, бер сүзле. Әтисе дә шулай сүзендә тора торган кеше иде. Ә бит, вәгъдәләр биреп тә, кире сүзләреннән кайтучылар да бар. Тәк, исәп буенча тагы 3,5 миллион сум акчаны кайдан табарга? Бүрекне кулга тотып район хуҗалыклары, эшкуар-алыпсатарларны йөреп чыгарбыз микән? – дип куйды.

Абзый үзе шулай сөйләнсә дә, күңеле белән Рима апа турында уйлаганы йөзенә үк чыккан. Шулай да, үзендә көч табып, Уфадагы скульпторларга шылтыратты. Алар эшне 20 гыйнварларга тәмамларга тиешлекләрен җиткерде.

...17 гыйнвар. Маллар карап йөрим. Хатыным Рәмилә, яныма чыгып:

– Римма апа мәңгелеккә кайтып киткән, – ди, үзенең күзләрендә яшь. – Тамагыма төер килеп тыгылды. Елап җибәрүдән чак тыелып торам. Хатыным сүзен дәвам итеп: – Әле генә Дәүләтьярова Люция шылтыратып әйтте, – диде дә, яшьләренә төелеп, өйгә кереп китте.

Башымда бертуктаусыз әллә нинди уй-хисләр әйләнеп бөтерелә башлады. Кичкә таба барча кайгылы хисләрне бергә төенләп, Ягъфәр абыйның хәлен белеп кайтырга була Стәрлебашка киттек.

...Менә Римма апаны да җирләп куйдык. Халык бик күп җыелды. Үзе мәктәптә укыткан укучылары, мәчеттә аңардан белем алганнар, барча ага-туганнар һәм таныштаныш булмаганнар да килгән. Римма Хәсән кызы районда бик тә хөрмәтле кеше иде шул. Хуш, Римма апа! Яткан урыннарың җылы һәм йомшак, якты булсын!

...Сөйләшеп вәгъдәләшкән көнгә Уфага бардык. Красноуфимскидан коючылар килде. Алар скульпторлар әзерләгән фигураларны алып китәргә әзерләнеп килгән. Ягъфәр абый коючыларга һәм скульпторларга акчаларны бүлеп бирде. Коючыларга 600 мең сум түләдек, чөнки аларга эшләрен дәвам итәр өчен бронза сатып алырга кирәк. Скульпторлар февраль урталарына барча эшләрне тәгәлләргә ышандырды. Уфадан исән-имин генә кайтып җиттек.

Күренеп тора: Ягъфәр абзыйның бер дә кәефе юк. Әйе, без, ирләр, үзебезне дөнья тоткасы итеп хис итсәк тә, артыбызда ышанычлы терәк, тылыбыз булмаса, эшләгән эшләребез ул кадәр үк була алмас иде. Римма апаны югалту безнең өчен бик тә авырга туры килде. Эшләгән эшебезнең яме, ашаган ашыбызның тәме беткән төсле булды...

2021 ел – Сыер елы. Әнкәй мәрхүмә гел әйтә торган иде: "Сыер елы – халык өчен бик тә авыр ел ул", – дип. Чынлап та шулай булды. Үзе безне бу изге эшләргә, дәртләндереп йөргән Зәки агабыз да март аенда мәңгелеккә күчте. Мин Казан каласында идем. Татар язучыларының сьезды барган чак. Һава торышы бик тә начар булу сәбәпле, Зәки абыйны җирләргә кайта алмадым. Юлларны япканнар. Нинди үкенечле хәл! Шулай итеп, Мөхәммәтшакир Тукаевка һәйкәл кую уе белән янып йөргән абзыебыз ниятенең нәтиҗәсен күрә алмады. Ярый әле, теге чакны һәйкәлен бушатканда килгән иде. Урыны җәннәттә булып, яткан гүрләре якты булсын.

...Ниһаять, Мөхәммәтшакир Тукаевның һәйкәлен китапханә алдына куярга рөхсәт иттеләр. Җиң сызганып эшкә тотындык. Егетләр тиз арада китапханә алдына яңа постамент төзеп тә куйды. Уфадан кара гранит плитәләр алып кайткан идек. Азат Фархшатов машина бирде. Стәрлетамактагы осталардан һәйкәл постаментына куеласы язуны яздырып алып кайттык. Красноуфимск каласына шылтыраттык. Андагы егетләр, килеп җитәрбез, дип вәгъдә бирде. Килүләренә башка җиһаз, кирәк-яракларны әзерләп куйдык. Фархшатов кибете тагы ярдәмгә килде, "ГАЗель" манипуляторы белән ярдәм итәрбез, диделәр.



*Бүгенге Стәрлебаш хатын-кызлары тыл хезмәтчәннәре ролендә.*

һәйкәлне урнаштырырга килгән егетләрне түземсезлек белән көтеп тора идек инде. Алар килгән көе Гаскәров Рим улының складыннан Тукаев һәйкәлен сак кына күтәреп алып чыгып машинага урнаштырдык. Китапханә алдына алып киләбез. Анда инде безнең эшләр белән таныш булган стәрлебашлылар җыелып өлгергән. Барча эшләрне төш вакытына тәмамлап, һәйкәлне урынына урнаштырып куйдык. Бик тә күркәм килеп чыкты. Үзебез дә бу кадәрле яхшы нәтиҗә көтмәгән идек. Әйтәләр бит, курыккан эш хәерле була, дип. Шулай булды да. Ниһаять, Мөхәммәтшакир Мөхәммәтхарис улы Тукаев үзенең лаеклы урынына торып басты.

Инде Зәки аганың "41нең арбалы хатыннары" пьесасындагы геройларга һәйкәл комплексы урнаштырасы бар. Ә менә безнең кассада җилләр уйный. Тагы 3 миллион 500 мең сум акчаны кайдан табарга? Сораулар һәм сораулар. Барча эш шул акча табу мәсьәләсенә килеп терәлде.

Әле тегеләй чабабыз, әле болай дигәндәй: юк, акчаның исе дә чыкмый. Депутатларга язган хатларны әйтеп тә тормыйбыз инде. Берсе дә дәшми. Халыкара хәлләр дә катлауланып тора.

2022 елның 17 гыйнвары. Сәгать 11гә хакимияткә чакыралар. Мөхәммәтшакир Тукаевның тууына 160 ел тула. Шәхесне хөрмәтләп һәйкәленә чәчәкләр салырга кирәк, диләр. Әйе, салдык. Иптәшем Рәмилә ханым белән бардык. Бик тә матур чара булды. Ни кызганыч, сәламәтлеге начараеп китү аркасында, чәчәк салу тантанасына Ягъфәр абый килә алмады.

...27нче гыйнвар көнне Ягъфәр абый белән башлыкка килдек. Ул һәрвакыттагыча ачык йөз белән безне каршылый. Безнең белән тагы ике яңа хезмәткәр дә керде.

Сүз шул куелачак һәйкәл турында бара. Акча кайдан табарга, дип сөйләшәбез. Сөйләшә торгач, "Салаватнефтеоргсинтез" оешмасы директорына хат язарга диган нәтиҗәгә килдек.

Башлык, сүзен дәвам итеп:

– һәйкәлгә урнаштырылган хатыннар реаль шәхесләр, дисез дә ул. Аларның исем-шәрифләре барысыныкы да билгелеме? Балалары исән микән?

– Төрлесенеке төрлечә инде. Әйтик менә, Хәйбулла белән Маһисәрвәр Фәйзуллиннарның олы кызы шушы ук Зәки Зәйнуллинның хатыны Суфия апа инде. Хәйбулланың сугыштан соң туган кызлары Хәлимә һәм Зәкия әлеге көндә Стәрлебашта яши. Хәлимә белән Зәкиянең кызлары да саусәламәтләр. Суфия апа – шушы хәлләрнең исән булган бердәнбер тере шаһиты. Әле Стәрлетамак шәһәрендә яши, – дим. Башкаларны да санап киттем.

***

һәйкәлдә сыннары сурәтләнгән хатыннарның кыскача биографияләрен язып үтәм. Менә алар:

**Маһисәрвәр (Сәрвәр) Ямалетдин кызы Фәйзуллина.** 1912 елның 28 маенда туган. Ире Хәйбулла Зәйнулла улы Фәйзуллин 1910 елның 8 гыйнварында дөньяга килгән. Икесе дә Стәрлебаш авылыныкы. Хәйбулла тәүдә мәктәптә, аннан "8 Март" колхозында эшли. 1933 елда кызлары Суфия һәм 1940 елда уллары Мансур туа.

Хәйбулла – Сәрвәрнең ире, сугыштан каты яраланып, култык таякларына таянып кайта. Гомере буе колхоз умарталыгында умартачы булып эшли. Сугышка киткәндә бергә алынган дуслары белән, кем дә кем исән кайта, шул сугышта ятып калганнарның балаларына ярдәм итәргә тиеш, дип сүз куешалар. Шушы вәгъдәгә тугры калып, ул гомере буе ятимнәргә кулыннан килгәнчә ярдәм итеп яши. Һич кыенсынмый. "Мин шушы ятимнәргә ярдәм итәр өчен исән кайттым. Аллаһы Тәгалә мине шуның өчен үлем тырнагыннан исән алып калды", – дия торган була.

Сәрвәр белән Хәйбулла 57 ел бергә яшиләр. Хәйбулла – 1986 елда, Сәрвәр 1988 елда 76

яшьләрендә мәңгелеккә күчәләр.

**Зифа Камәретдин кызы** 1922 елның 24 сентябрендә Стәрлебаш авылында туа. Колхозчы. Ире Абдулла Әхмәтов райком комсомолында эшли. Сугышта һәлак була. Өйләнешеп, барлыгы өч ай гына бергә яшәп калалар. Зифа сугыштан соң яңадан кияүгә чыгып биш бала үстерә. 1998 елда 76 яшендә бакыйлыкка күчә. Әлеге көндә кызлары Флүрә белән Зәйтүнә Стәрлебаш авылында яши.

**Маһиәсма (Әсма) Гобәйдулла кызы** 1923 елның 12 маенда шушы ук Стәрлебаш авылында якты дөньяга килә. Мәҗит Галиев – 1920 елгы. Шулай ук, барлыгы өч ай гына бергә яшәп калалар. Мәҗит сугышның тәүге көннәрендә үк хәбәрсез югала. Вакыты җиткәч, уллары Марс туа. Әсма башкача кияүгә чыкмый. Гомере буе пекарняда эшләп, хаклы ялга чыга. 2005 елда 86 яшендә дөнья куя. Оныгы Талбазыда яши.

**Миңнеямал** 1910 елда Стәрлебаш авылында дөньяга килә. Ире Сәлахетдин Зәйнетдинов колхозда ат карауч булып эшли. Миңнеямал төрле эштә шушы ук "8 Март" колхозында эшли. Сугышка кадәр уллары Гайнетдин (1931), кызлары Мәрьям (1937), кече уллары Мөнир (1941) дөньяга килә. Менә шушы гыйнвар аенда туган кече улын, ничек тәпи атлаганын күрсен дип, Миңнеямал үзе белән Раевка стансасына, ире Сәлахетдингә күрсәтергә алып бара. Сәлахетдин сугышта һәлак була.

Миңнеямал, олы улы Гайнетдин һәм килене Кифая белән бергә яшәп, 1985 елда 74 яшендә дөнья куя. Хаклы ялга чыкканчы "Стәрле" колхозында эшләде. Оныгы Фәнил Зәйнетдинов үзенең гаиләсе белән Стәрлебашта яши. Әниләре Кифая апаны карыйлар.

**Мөнәвәрә** 1916 елгы. Ире Абдулла Искәндәров сугышка кадәр шофер булып, икесе дә "8 Март" колхозында хезмәт куялар. Сугышка чаклы уллары Җәүдәт 1936 һәм 1938 елда кызлары туа. Абдулла сугыштан исән-имин кайта. Калган гомерләрен бергә яшиләр. Мөнәвәрә бик кыю һәм үткер хатын була. Раевкага сәяхәтне оештыручыларның берсе. Кызлары Стәрлетамак каласында яши.

**Рәйханә Муллаәхмәт кызы** 1910 елгы, Әмир авылында туа. Ире Йосыпов Миңнебай – Стәрлебаш егете. Гәүдәгә бик таза булып, эшкә бик талымсыз була. Сугышка чаклы Габдерәшит (1935), Габдрәхим (1937), кызлары Сәбилә (1939) туа. Шулай ук икесе дә "8 Март" колхозында эшлиләр. Рәйханә йөзгә дә гәүдәгә дә бик матур була. Кул эшләренә бик оста һәм уңган, тырыш хатын. Ире Миңнебай янына барырга дип, иң күп азык-төлекне ул әзерли. Миңнебай сугышта батырларча һәлак була. Рәйханә апа олы улы һәм килене Халидә белән гомере буе бергә килешеп яшәде. Килененә дустәнә сердәш булып гомер кичерде. 1980 елның 14 апрелендә бакыйлыкка күчте. Кызы Сәбилә Стәрлетамакта яши. Килене Халидә апа, оньк-туруннары Стәрлебашта яшиләр.

* * *

Зәки ага Зәйнуллинның елын үткәрәбез дип, күптән үк ниятләп куйган идек. "Амазонка" кафесын Ягъфәр абзый алдан ук 4 мартта сөйләшеп, барчасын да ул оештырды. Тәтер-Арслан, Айдәрәле һәм Стәрлебаштан Зәки аганың фикердәшләре һәм аны яхшы белгән абзый-апалар җыелды. Коръән аятьләре укып, Зәки ага турында хатирәләрне искә төшереп утырдык.

Март аеның 24ендә Ягъфәр абыйның кызлары Уфага алып киттеләр. Операция ясарга тиешләр. Ниһаять, аны 14 апрельдә хастаханәдән чыгардылар. Якшәмбе көнне барып хәлен белеп кайттым. Кәефе болай шат кына күренә. Алдагы көннәрдә башкарасы эшләр турында сөйләштек. Һәйкәл өчен җитмәгән сумманы җыеп бетерәсе бар. Башка мәшәкатьләр дә җитәрлек. Ягъфәр абзый Акмулла фондының 30 еллыгын үткәрүне кайгырта башлады.

2024 ел, ноябрь. Дүшәмбе көн. Ягъфәр абый белән Стәрлетамак районына киттек, әлеге шул һәйкәлләргә әзрәк акча алып булмасмы дигәннеке инде. Бер оешма җитәкчесенә ияреп бүлмәсенә үк керәбез. Үзе былтыр ук вәгъдә иткән әз-мәз булса да акчаны алып булмасмы, дип сөйләшә башладык. Сөйләшүеннән ук сизелеп тора: ярдәм булмый.

– Менә без тегендә акча бирдек, шунда ярдәм иттек. Гомумән, сез, абзыйлар, рәкет ясап йөрмәгез. Хушыгыз, хуш! Минем хәзер планерка башлана, – ди.

Мин түзмәдем:

– Безнең кулда корал да юк, кесәдә пистолет та йөртмибез, – дим.

– Рәкетирлар сез, барыбер рәкет белән йөрисез.

Нишлисең, хушлашып чыгып киттек. Шулай итеп, безне рәкетирлыкта гаепләп ташладылар. Ярар, ни хәл итәсең. Шул һәйкәлләргә акча җыябыз дип, әллә нинди гаепләүләр дә ишетергә туры килгәләде.

Иртәгә күрше районындагы бик бай хуҗалыкка, якташыбыз янына барырга план кордык. Анда нәрсә булыр. Анысын бер Аллаһ кына белә. Ике миллион акчаны кайдан табарга? Бардык, күрдек һәм сөйләштек. Аллаһка шөкер, өч йөз мең акча күчерде.

Бүген февраль аеның уны. Ягъфәр абый белән хакимияткә керергә сөйләшкән идек. Кабул итүчеләрдән икенче булып керәбез. Башлык махсус хәрби операциягә гуманитар конвойны озатып, исән-имин йөреп кайткан, хәлен белешәбез.

Рөстәм Камил улы безнең нинди йомыш белән йөргәнне белеп тора. Мин инде:

– Соңгы терәк, соңгы ышаныч сездә калды, – дим.

Ягъфәр абый да:

– Сездән башка бер миллион җиде йөз сум акчаны ничек җыеп бетерә алабыз соң? Менә карагыз, күпме акча җыясы калды да кемнәр күпме акча бирделәр, – дип, язып алып килгән хатны суза.

Сөйләшә торгач, 24нче февральдә тагы очрашып сөйләшергә вәгъдәләштек.

Икенче көнне, Ягъфәр абзый янына килдем. Шуннан яңадан райондагы оешмаларны һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен барлый башладык. Ягъфәр абый барысына да мөрәҗәгать хатлары әзерләргә булды. Мин үзем "Ислам нуры" мәчет әһелләренә мөрәҗәгать итәчәкмен.

Менә җомга көн килеп җитте. Кәтеп алдым. Мәчет әһелләре белән бергәләп җомга намазын укыдык. Намаздан соң хәзрәттән рөхсәт алып, әлеге шул һәйкәлләргә акча җыю турында сөйләдем. Шунда бер абзый миңа, һәйкәл фондына дип, ару гына акча сузды. Алмадым. Чөнки акча эше бит. Бу эш белән Ягъфәр абзый шөгыльләнә. Исемлеккә язып, акча биргәнгә һәм алганга имза куярга кирәк. Шунсыз булмый. Югыйсә, кайбер бәндәләр "җыелган акчаны үз мәнфәгатьләренә тоталар" дигән ялган фикер-гайбәт тә тарата. Аллаһ сакласын андый гөнаһлы эшләрдән.

Аллаһыга шөкер! Райондашлар ныклы ярдәм иттеләр. Олы яшьтә булуларына карамастан, Миңнур Бикмөхәмматова, Куганакбаштан Әнвәрә Мөлекова, Тәтер-Арсланнан Нәфисә Латыйпова-Рысаева өйдән өйгә йөреп хәтсез генә акча җыеп тапшырдылар. Шулай ук Яңгырчы авыл хакимияте башлыгы Дамир Кунафинга да зур рәхмәтебезне белдерәбез. Башка ярдәм итүчеләргә дә бик зур рәхмәтләребез! Аллаһ Тәгалә саваптан әйләсен!

* * *

Ниһаять, авыл Советлары акча җыеп тапшыра башлады. Кайберләре матур гына сумма җыйганнар.

Атна саен дүшәмбе көнне хакимияткә җыелабыз. Беренче урынбасар кайсы эшкуар, кайсы оешма күпмерәк акча җыюга исәп-хисап тота. Ярдәм бик җай җыела. Ничек кенә булмасын, ике һәйкәлгә җәмгысы 10 миллион 71 мең сум акча тупланды. Бу Стәрлебаш районы халкының, аның илсөяр улы һәм кызларының, районыбыз дусларының олы җиңүе иде!

Шушы урында иң зур матди ярдәм күрсәтүче шәхесләрне санап үтәсем килә. Менә алар: Зәки Зәйнуллин, Ягъфәр Хисмәтуллин, Ирек Арсланов, Азат һәм Алмас Максютовлар (икесе бергә) – берәр миллион сум, күренекле меценат, Куганакбаш авылында туып-үскән Марат Ишмияров 2,5 миллион сум акча күчерде.

14 апрельдә Ягъфәр абый һәйкәлне Красноуфимск каласыннан 23ендә китерәчәкләр дип, белдерү ясады. Шуңа чаклы коючыларга акча әзерләп торырга тиешбез. Шушы ук көнне һәйкәлне ничек ачу турында да сөйләшү булды. Ачу тантанасын май азакларына, июнь башларына билгеләргә килешенде, чөнки Җиңү көнендә болай да тантаналы чаралар күп булачак.

23.04.2025. Таң белән торып, Красноуфимскидан киләсе кунакларны каршы алырга әзерләнәм. Көн бигрәк тә матур. Һавада тургайлар сайраша. Җил дә юк. Стәрлетамактан район үзәгенә керә торган юл боҗрасында көтәм. Менә Ягъфәр абый да килеп җитте. Кунаклар Оренбург трассасыннан безнең якка борылган икән. Әле генә шылтыратып хәбәр бирделәр. Сәгать алга йөгерә. Тугыз тулып килә. Ягъфәр абый:

– Мин сельхозбанкка барам. Банк ачылуга анда булырга тиешмен, – дип, банкка чапты.

Мин көтәм. Менә кунаклар да (һәйкәлне коючылар) килеп җитте. Йөк машиналары кайдалыгын белешәм. Алар:

– Һәйкәлләрне төягән машина күптән безне зират кырында көтә, – диләр.

Алга кузгалабыз. Чынлап та йөк машинасы безне көтеп тора иде. Бергәләп һәйкәл ансамбле урнашасы урынга, клуб алдына килеп туктадык.

Кунакларны "Савой" кунакханәсенә алып киттем. Милләтебезнең кунакчыллык йоласына тугры калып, һәйкәл коючыларны иртәнге чәй эчереп, ашатып алып килдем. Без



*Иганәче Марат Ишмияров.*

Мәдәният сарае алдына килеп җитүгә, Ягъфәр абый да анда килеп безне көтеп тора.

Фәхриев Азат та үзенең краны белән килеп җиткән. Эшчеләр дәррәү эшкә тотынды. Эшне белеп эшлиләр. Һәйкәл сыннарын бик саклык белән генә бушата башладылар. Һәрберсен яхшылап төреп салганнар. Алар сыннарны бушата, ә минем күзләргә яшь төелде.

Сак кына Ягъфәр абыйга карыйм. Ул зур дулкынлану белән эш барышын күзәтә. Күрәм, аның да күзләрендә яшь бөртекләре ялтырый. Әйе егетләр, бу безнең өчен бик тә дулкынландыргыч минутлар иде...

*Фотолар "Стәрлебаш чишмәләре" гәзитеннән һәм башка чыганаклардан алынды.*




***Стәрлебашлылар һәйкәл ачу тантанасында.*** *2025 ел, 20 июнь.*